| ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 ел, 03 ноябрь Петровский Завод авылы № 8

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Петровский Завод авылы гражданнары җыенын Петровский Завод авылы мәдәният йорты бинасында 2023 елның 15 ноябренә: 11 сәгать 00 минутка хэм 14 сэгать 30 минутка.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2024 елда үзара салымны 450 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) гомуми автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге файдалану:

- Петровский Завод торак пунктында Беларус-82,1 тракторын тоту (водитель хезмәтләренә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Петровский Завод торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

- Петровский Завод авылы Үзәк урамында юл ремонты (таш белән капланган чокыр ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
- җирле әһәмияттәге юллар буендагы коры агачларны, куакларны кисү (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Петровский Завод торак пункты территориясен чабу өчен триммерлар сатып алу;
- Петровский Завод торак пункты тракторы өчен чапкыч сатып алу;
2) урам яктырту җайланмасы:
- Петровский Завод торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ;
3) Петровский Завод торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү:
- (территорияне чабу һәм коры агачларны кисү);
зират территориясен саклау өчен материаллар сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
4) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:
- су күтәрү манарасы һәм насос өчен будка территориясенә койма тоту өчен материаллар сатып алу, койма урнаштыру буенча хезмәтләр өчен түләү;
5) халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
- Петровский Завод торак пунктында балалар мәйданчыгын ремонтлау һәм койма тоту өчен материаллар сатып алу, койма урнаштыру буенча хезмәтләр өчен түләү;
6) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү капчыкларын сатып алу);
7) Петровский Завод авылында мәдәни чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май);

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенен мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Нуртдинов